Муниципальное бюджетное
дошкольное образовательное
учреждение «Центр развития
ребенка- детский сад
**№ 85 «КАРУСЕЛЬ»**
423800, Республика Татарстан,
город Набережные Челны,
улица Николая Мальнева, зд.1

**«КАРУСЕЛЬ» 85 нче**
балалар бакчасы-баланы
аң-белемен үстерү үзәге»
муниципаль бюджет мәкт
белем бирү учреждениес
423800, Татарстан
Республикасы,
Яр Чаллы шәһәре,
Николай Мальнев
урамы,1нче бина

Электронный адрес: sad85karusel@mail.ru

КИЛЕШЕНДЕ
Өлкән тәрбияче вазифаларын башкаручы
______________ И.А.Мартынова
«28» август 2024ел
№ карар нигезендә кабул ителде
«28» август 2024ел

РАСЛЫЙМ
«КАРУСЕЛЬ» 85 нче
балалар бакчасы-баланың
аң-белемен үстерү үзәге»
МБМББ җитәкчесе
вазифаларын башкаручы
______________ Г.Д.Ханнанова
Педагогик киңәшмәдә каралган һәм
«28» август 2024ел
Беркетмә № 1

# 8 нче номерлы икенче кечкенәләр төркеменең (3-4яшь) 2024-2025 нче уку елына эш программасы

Төзүче: Г.Ә.Идиятуллина

Яр Чаллы шәһәре
2024нче ел

**Эчтәлек.**

Аңлатма язуы

**I нче бүлек**

1.1.Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге.

1.2.Программаның төп максатлары

1.3. Программаның төп бурычлары

1.4. 3-4 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре

1.5. 3-4 яшьлек балаларның уку елы азагындагы максатчан күрсәткечләре

1.6. Икенче кечкенәләр төркеме өчен көндәлек режим (3-4 яшь).

**II нче бүлек**

2.1.Икенче кечкенәләр төркеме өчен белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

2.1. 1.”Физик үсеш “ юнәлеше

2.1.2.“Социаль-шәхси үсеш”юнәлеше

2.1.3.“Танып белү-сөйләм үсеше”юнәлеше

2.1. 4.”Нәфис-нәфасәти үсеш “юнәлеше

2.2. Программаның милли-төбәк компоненты

2.2. 1.Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып кечкенәләр төркемендә тәрбия һәм укыту бурычлары.

2.3. Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып юнәлеш эчтәлеге

2.4. Комплекслы-тематик план.

**IIIнче бүлек**

3.1. Балаларның гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планлаштырылган нәтиҗәләр

3.2.Төркемнең материаль-техник нигезе

3.3.Ата - аналар белән эш

**Аңлатма язуы**

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына, Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр” төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына, балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Учредитель: Муниципальное образование город Набережные Челны. Функции и полномочия учредителя осуществляет Исполнительный комитет муниципального образования город Набережные Челны.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**

**«КАРУСЕЛЬ» 85 нче** балалар бакчасы-баланың аң-белемен үстерү үзәге»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»

**Кыскача атамасы** : “Карусель” 85 нче балалар бакчасы МБМББУ.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**

*РФ субъекты:* Татарстан Республикасы
*индекс*: 423800,
*шәһәр:* Яр Чаллы шәһәре
*урам:* Николай Мальнев
*йорт:* 1
*шәһәрнең федераль телефон коды:* (8552) *телефон:* 49-32-03
*электрон адрес*: sad85karusel@mail.ru

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**
Гөлнара Данил кызы Ханнанова

**Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2024-2025 уку елы)**

Эш программасы түбәндәге норматив документлар буенча яраклаштырылган:

**Федераль дәрәҗәдә**:

- “Рәсәй Федерациясендә белем алу” турындагы 273 номерлы 2012 елның 29 декабрь Федераль законы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең”;
- “Федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау” турындагы 1155 нче номерлы 2013 ел 17октябрь приказы;
- «Белем алу турында» РТ законы;
- программам - образовательным программам дошкольного образования;
- Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 20.09.2020 г.№28»Об утверждении санитарных правил СП 2.4.3648-20

«Санитарно-эпидемиологическиетребования к оргагизациям воспитания и обучения,отдыха и оздоровления детей и молодёжи»

Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.01.2021 №2 «Об утверждении санитарных правил и норм Сан Пин1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания» (вместе с СанПин 1.2.3685-21.Санитарные правила и нормы…»)

- Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима дошкольных образовательных учреждений (СанПиН 2.4.1.3049-13);

**Региональ дәрәҗәдә**:

Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 г. № 68-З РТ "Об образовании"
Закон Республики Татарстан "О языках народов Республики Татарстан" № 1560-XII от 8 июля 1992 года

**Җирле дәрәҗәдә**:

Устав МБДОУ № 85 «Карусель»

Годовой план работы на текущий учебный год.

**Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары.**
**Эш программасының максаты:**

- Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларны физик, интеллектуаль, шәхси сыйфатларын үстерү.

**Эш программасының бурычлары:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.

2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.

3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

**Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;

*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;

*Балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;

*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;

*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;

*Балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эш эчтәлеген, эш төрләрен, эштә иптәш сайлау хокукы бирү.

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**

1. Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2. Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы).
3. Сәламәтләндерү һәм профилактика чаралары.

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына **түбәндәге бурычларны куя:**

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3. Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. “Татарстан Республикасы халыклары телләре” турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камилллләштерүне дәвам итү.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

Бүгенге көндә балалар бакчасында 11 төркем: 4 татар һәм 7 рус төркемнәре эшләп килә.

**Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары.**

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга, бу балачакның мәктәпкәчә чорының үзкыйммәтен тану турындагы хәзерге фәнни «Мәктәпкәчә тәрбия концепциясе»нә (авторлары В.В. Давыдов, В.А. Петровский һ.б.) туры килә. Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән. Программада балаларның белемен катгый регламентацияләү һәм укытуда предметлы үзәкләштерү юк. Программаны эшләгән вакытта авторлар мәктәпкәчә белем бирүнең ил-күләм иң яхшы традицияләренә, аның фундаментальлегенә: балаларның тормышын саклау һәм сәламәтлеген ныгыту буенча бурычларны комплекслы хәл итүгә; һәрьяклы тәрбиягә; балалар иҗат эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру нигезендә үсешне баетуга (амплификацияләү) таяндылар. Программада мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төп әһәмияткә ия уен эшчәнлегенә аерым урын бирелә (А.Н. Леонтьев, А.В. Запорожец, Д.Б. Эльконин һ.б.). Программа авторлары аеруча мөһим дидактик принципны — үсешкә китерүче укытуны һәм Л.С. Выготскийның дөрес оештырылган укыту үз артыннан үсешне «ияртә» дигән фәнни нигезләмәсен исәпкә алып эш иттеләр. Тәрбия һәм психик үсеш икесе аерым, бер-берсе белән бәйләнмәгән процесс буларак карала алмыйлар, әмма бу очракта «тәрбия бала үсешенең кирәкле һәм гомумкүләм формасы сыйфатында хезмәт итә» (В.В.Давыдов). Шулай итеп, Программа кысаларында үсеш балаларга тәрбия һәм белем бирүдә уңышлылыкның иң мөһим нәтиҗәсе булып тора. Программада баланы туганнан алып мәктәпкәчә тәрбияләүнең һәм аңа белем бирүнең барлык төп эчтәлек юнәлешләре комплекслы күрсәтелә. Программа мәдәни ярашканлык принцибына корылган. Әлеге принципны гамәлгә ашыру белем бирүдә милли кыйммәтләрне һәм традицияләрне исәпкә алуны тәэмин итә, рухи-әхлакый һәм эмоциональ тәрбия бирүдәге җитешсезлекләрдән арынырга булыша. Белем бирү баланы кешелек мәдәниятенең төп компонентларына (белем, әхлак, сәнгать, хезмәт) якынайту процессы буларак карала. Программа материалын сайлауның төп критерие — аның тәрбияви кыйммәте, кулланылган мәдәният әсәрләренең (илебез, шулай ук чит илләр классикасы һәм халык иҗаты) югары сәнгатьлелек дәрәҗәсе, мәктәпкәчә балачакның һәрбер этабында баланың һәрьяклы сәләтләрен үстерү мөмкинлеге (Е.А. Флерина, Н.П. Сакулина, Н.А. Ветлугина, Н.С. Карпинская). «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы:

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту

максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;

• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;

• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;

• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;

• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрлеләндерүгә юл куя;

• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләренең иң җаваплы, изге бурычы-балаларны кечкенәдән инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле, белемле һәм сәламәт итеп үстерү. Бүгенге көндә милли әхлак тәрбиясенә, нәниләрне халкыбызның күркәм традицияләре: рухи-әхлакый һәм милли –мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләүгә җитди игътибар бирелә. Тәрбия эше берьяклы гына була алмый. Ул уңышлы, нәтиҗәле булсын өчен, гаилә һәм бала йөри торган балалар бакчасы алып барган тәрбияви чаралар, алга куйган бурычлар, аларны үтәү юллары берберсенә теләктәш булырга тиеш. Шулай итеп, гаиләдә нигез итеп салынган күнекмәләр балалар бакчасында тагын да үстерелә, камилләштерелә. Тәрбиянең нигезендә аралашу чарасы булып- ана теле ята. Ана теле, ягъни туган тел аша үзләштерелгән идеяләр, белем һәм күнекмәләр хәтергә көчлерәк сеңә.

Балалар бакчасында тәрбия эше эчтәлеген яңарта бару, инновацион технологияләрне куллану-тормыш таләбе. Бүген тәрбия эчтәлеге күпкырлы һәм ул үзенә түбәндәге өстенлекле юнәлешләрне берләштерә: балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеген саклау, ныгыту, интеллектуаль тәрбия бирү һәм үстерү, шәхестә культуралылык сыйфатлары һәм рухи кыйммәтләр булдыру; гражданлык тәрбиясе һәм патриотик тәрбия бирү, гаиләнең шәҗәрәсен өйрәнү һ.б.

Без,тәрбиячеләр,ата-аналар белән бергә үзебез өчен киләчәк әзерлибез. Шулай булгач, киләчәгебез матур, өметле, ышанычлы кулларда булсын дисәк, дөньяга аңлы карашлы, аек фикер йөртә белгән, кулыннан эш килгән, алдан күрә белә торган, шәфкатьле, хезмәт яратучы, сау-сәламәт балалар үстерик.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр,мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы» нигезендә төзелгән. Методик кулланмада федераль дәүләт таләпләре буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем

бирү өлкәләрен үәштерү гомуми кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып эшләнде. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик яклanганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә

# I бүлек

## 1.1.Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге

Вакыт илебезнең мәгариф учрежденияләре эшенең яңа иҗтимагый-икътисади шартларда алып барылыу мәктәпкәчә мәгарифне заман таләпләренә туры китереп үзгәртүне, дәүләт һәм гаиләнең бала тәрбияләүдәге ролен яңа прогрессив формалар белән баетуны, һәр баланың эмоциональ иминлеге һәм төрле яклы үсеше өчен педагогик коллективның җаваплылыгын арттыруны таләп итә. Бүгенге мәктәпкәчә мәгарифнең приоритетлары үзгәрү сәбәпле, балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаларын яңартырга кирәкле булды. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учрежденияләре хезмәткәрләре, яңа заман таләпләрен исәпкә алып, башка концептуаль нигезендә төзелгән программалардагы мәсьәләләрне һәм эчтәлекне әлеге документка мөстәкыйль рәвештә кертәләр. Шулардан чыгып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем процессында “Физик үсеш”, “Социаль-шәхси үсеш”, “Танып белү-сөйләм үсеше”, “Нәфиснәфасәти үсеш” юнәлешләре булуы мөһим.

План балалар бакчасында икенче кече яшьтәге балалар белән эшләү өчен ФГОС , Р. К. Шаехованың “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Ф.В Хәзрәтованың “Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик кулланмасы нигезендә балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү, тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру максатыннан чыгып төзелде. Методик әсбап танып белү, сөйләм үстерү, матур әдәбият белән таныштыру кебек белем бирү өлкәләрен үз эченә ала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар — «Безнең балалар бакчасы», «Көз», «Минем әйләнәтирәм», «Кыш», «Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр», «Халык иҗаты»,«Яз», «Җәй».

Ф.В Хәзрәтованың “Туган телдә сөйләшәбез” укыту методик кулланмасында ФГОС буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып үткәрелә.

Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.

**I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан-туры таныштыру**

1.Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.

2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзе, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәте турында күзаллаулар) белән таныштыру.

**II. Образлы уенчыклар аша тирә-юнь белән таныштыру**

1.Уенчыклар карау.

2. «Тылсымлы» капчык», «Бу өйдә кем (нәрсә) яши?» дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.
3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.
4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

**III. Рәсем сәнгате аша әйләнә-тирә белән таныштыру**

1.Өстәлгә куела торган кечкенә рәсемнәрне, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.

2. «Җанлы» кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

**IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру**

1. Халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләре уку.
2. Тәрбияче белән бергә кыска әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

**V. Күрсәтмәлелектән башка, тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү**

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуациядән тыш, тәрбияченең сөйләве.
2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр.

Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш,

аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары хәл ителә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү мәсьәләләрен чишкәндә, өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла.Шундый чараларның берсе-бармак уеннары. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л. С. Выготский, И. П. Павлов, А. Р. Лурия, А. А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Программа балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү, рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура, туган якны, туган (татар, рус) телне өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота. «Милли культураны, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны шушы җирдә яшәгән башка халыклар культурасы белән баету, баланың культурага булган билгеләмәсе киләчәктә аңа бөтендөнья культурасын аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз халкының культурасына булган шундый киң караш, аны зуррак масштабтагы культура процесслары контекстларында кабул итү генә иҗади шәхес формалашуга һәм үсешенә нигез булып торачак, ул үз чиратында милли культураны пассив күзәтергә генә түгел, ә аңа шәхсән үз өлешен кертергә, культура барлыкка килү процессында катнашырга мөмкинлек бирәчәк» (Ф. Ф. Харисов)

### 1.2. Программаның төп максатлары:

- Һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында һәр яктан үсеш алуы турында кайгырту;
- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлеген төрле төрләрен киң куллану, укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану, белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү;
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмасы һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;

-гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм мәктәпкәчә
оешманың тормышында катнашуын тәэмин итү; -
балалар бакчасы эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага
артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

### 1.3. Программаның төп бурычлары:

-Балаларның сәламәтлеген ныгытуга комплекслы килү, аларның психик-эмоциональ иминлеген тәэмин итү.

-Әйләнә-тирә дөньяга, туган гаиләсенә, туган йортына, туган җирлегенә, Туган иленә, төрле милләт кешеләренә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

-Балаларда сәламәт тормыш рәвеше белән яшәү зарурлыгы булдыру, үз сәламәтлеге өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.

-Мәктәпкәчә яшьтә белем бирүне тәэмин итү.

-Балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.

-Балаларда гражданлык хисләре тәрбияләү.

-Психолог ярдәме белән балаларга белем бирү эшчәнлегендә барлыкка килгән кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү.

-Балаларның тулы куәтле үсешен тәэмин итү максатларында гаиләләр белән элемтәләрне ныгыту.

-Белем бирү һәм тәрбия эчтәлеген, шартларын, технологияләрен модернизацияләү юлы белән белем бирү процессын яңарту.

## 1.4.3-4 яшьлек балалар үсешенең яшь үзенчәлекләре

Әлеге чор дәвамында төрле юнәлешләр буенча сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Уен, рәсем, төзү кебек эшчәнлек төрләре камилләшә. Безнең күз алдында 3—4 ел дәвамында балаларның игътибары, хәтере, фикерләве, күзаллавы, сөйләме көчле үсеш ала. Гади җөмләләр катлаулылары белән алышына һәм кызыклы кечкенә хикәяләргә әверелә. Бу яшьтә баланың дуслары барлыкка килә башлый, ул зурлар белән теләп аралаша, үз тәртибен көйли. Дөнья турында күзаллавы киңәя һәм «нигә?», «ни өчен?» сораулары җавап таләп итә. Мәктәпкәчә яшь чорының башы 3 яшьтәге кискен үзгәреш белән туры килә. Иртә яшьтә үсеш һәм тәрбия дөрес оештырылган булса, баланың 3—4 яшьтә буе 90—100 смга җитә, гәүдә авырлыгы якынча 13—16 кг була. Аның җитезлеге арта, тизрәк йөгерә, яхшырак сикерә, ыргыткан тупны ике кулы белән тотып ала. Әле 2 яшьтә ул бу хәрәкәтләрнең берсен дә эшли белми иде! 3—4 яшьтә балалар физик яктан көчлерәк, мөстәкыйльрәк. Физик тәрбия акыл тәрбиясе белән бәйләнештә алып барыла. Бу яшьтә акыл, эстетик, әхлак, физик үсеш югары темп ала. Мәктәпкәчә яшьтәге бала әйләнә-тирә дөньяны танып белә, күзәткән вакыйгаларны, күренешләрне аңларга тырыша. Дөрес оештырылган педагогик процесс нәтиҗәсендә балалар төрле төшенчәләрне үзләштерәләр, нәтиҗәләр чыгаралар, гомумиләштерәләр. Балаларның кызыксынучанлыгы, яхшы хәтере аңа күп информация тупларга ярдәм итә. Кызыксынучанлык баланы эзләнү эшчәнлегенә (Н.Н.Поддьяков), зурларга сораулар белән мөрәҗәгать итәргә стимуллаштыра. Сораулар характеры буенча баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләргә була. 3—4 яшьлек баланың аралашуы гаилә белән генә чикләнми. Зурлар бала өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә билгеле иҗтимагый функция үтәүче булып та тора. Баланың шундый ук функция үтәргә теләве аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Әлеге каршылык» мәктәпкәчә яшьтә әйдәүче эшчәнлек — уен аша чишелә.

Уенның төп үзенчәлеге, аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар уенда берике роль һәм гади сюжетлар белән чикләнәләр. Кагыйдәле уеннар әле формалаша гына башлый.

3-4 яшьлек балаларның эшчәнлеге катлаулана һәм төрләләнә: алар уку һәм хезмәт биремнәрен уеннар аша аера башлыйлар. Уен һәм шөгыль нәтиҗәсендә психик процесслар (хәтер, фикерләү, игътибар, күзаллау) үсеш ала, балаларның яңа ихтияҗлары һәм мәнфәгатьләре барлыкка килә. 3-4 яшьлек балалар үсешендә сәнгать эшчәнлеге мөһим урын алып тора. Әлеге эшчәнлек баланың предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә күзаллаулар формалаша гына башлый. График образлар ярлы. Кайбер балаларның рәсемнәрендә детальләр төшеп кала, ә икенчеләре киресенчә, җентекләп ясый. Балалар рәсемнәрдә төрле төсләр куллана башлый. Кул моторикасын үстерү өчен әвәләү, бармаклар гимнастикасы зур әһәмияткә ия. Кече мәктәпкәчә яшьтә балаларның төзү эшчәнлеге, үрнәк буенча һәм уйлап чыгарылган катлаулы булмаган төзелешләр белән чикләнә.

Әлеге яшьтә аерым эшчәнлекләр үсеш ала. Балалар башлангыч эталоннарны (кабул итүнең индивидуаль берәмлекләре) кулланудан сенсор эталоннарга (кабул итүнең эшкәртелгән чаралары) күчәләр. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына балалар предметларның һәм төсләрнең биштән алып җиде төренә кадәр аералар, предметларны зурлыгы буенча дифференциациялиләр, балалар бакчасының төркем бүлмәсе, белем бирү процессын оештырганада, бөтен балалар бакчасы бинасы пространствосында ориентирлашалар.

Хәтер һәм игътибар үсеш ала. Зурлар үтенече буенча балалар 3-4 сүз һәм 5-6 предмет исемен хәтерләрендә калдыралар. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына алар яраткан әсәрләрдән өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-хәрәкәт фикерләве үсеше дәвам итә. Шуның белән беррәттән, кайбер очракларда, теләгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, мак-сатчан үрнәк нигезендә ситуация үзгәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешне билгеләргә сәләтле. Кече мәктәпкәчә яшьтә күзаллау үсеш ала  һәм ул бигрәк тә уенда чагылыш таба. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнә. Максатчан тәэсир итү нәтиҗәсендә, алар үзләренең һәм башка балаларның эшләрен бәяләү өчен ни-гез булган, чагыштырмача зур күләмдә нормаларны үзләштерә алалар. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт бигрәк тә уем эшчәнлегендә ачык чагыла. Шулай ук бу яшьтә сайлауга корылган үзара мөнәсәбәт тә күзәтелә. Уенчык сайлауга бәйле конфликтлар килеп чыга. Төркемдә баланың иптәшләре арасында тоткан урыны тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Кече мәктәпкәчә яшьтә чагыштырмача гади генә ситуациядә тәртип һәм мотивның бер-берсенә буйсынуы күзәтелә. Тәртип белән аңлы рәвештә идарә итүгә әле нигез генә салына, күп очракта баланың тәртибе ситуатив характерда. Шуның белән беррәттән, сүзле күрсәтмәләр ярдәмендә баланың үз теләген үзе чикләвен күрергә була. Балалар үз мөмкинлекләрен бәяли оашлыйлар, ләкин тәрбияче бәяләмәсенә ориентирлашалар.

### 1.5 3-4 яшьлек балаларның уку елы азагындагы максатчан күрсәткечләре.

-Бала эшчәнлек вакытларында, аралашу вакытында, танып белүдә, рәсем ясаганда,әвәләү вакытында,конструкцияләүдә теләп катнаша. Үзенең инициативасын күрсәтә һәм мөстәкыйль эш итәргә тырыша.

-Бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән хезмәттәшлек итә, уртак уеннарында катнаша; башкаларның мәнфәгатьләрен һәм хисләр исәпкә алып үзара килешеп эш итә, аларның уңышларынана куану һәм кайгыларын уртаклашу хисләрен белдерә.

-Бала үзенең тәэсирле хисләрен төрле ысуллар аркылы күрсәтә белә, тискәре хисләрен тыеп тора; якыннарының , дусларының һәм әйләнәтирәдәгеләрнең эмоциональ хәленә кереп, ярдәм итәргә әзер , хикәядәге геройларның, экият персонажларының хәленә кереп, алар өчен борчыла; хисләр белән сугарылган сәнгать әсәрләренә, рәсем сәнгатенә, музыкага, табигать матурлыгына соклана һәм ләззәтлләнә; хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын кайгырта. -Бала кызыксынучанлык күрсәтә, табигать күренешләрен һәм кешеләрнең башкарган гамәлләрен күзәтергә һәм аңлатырга омтыла.Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә һәм әйтә белә:яңгыр,кар ява... Табигать матурлыгына соклана белә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын кайгырта.

-Бала яше буенча хәрәкәтле, дидактик, с.рольле, өстәл уеннарын белә.Баланың эре һәм вак моторикасы үсеш алган; ул хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәтләрне үзләштергән, алар белән идарә итә һәм үзен контрольдә тота.Хәрәкәтле уеннарда теләп катнаша.

-Бала ихтияр көченә ия, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашканда, эшчәнлек барышында ,үз-үзеңне тоту нормаларын һәм кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үти.Көнкүреш әйберләреннән (кашык, тарак , карандаша һ. б.) белән файдалана белә.

- Әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль рәвештә яки сораганда "рәхмәт", "исәнмесез", "сау бул", "тыныч йокы" сүзләрен (гаиләдә, төркемдә) әйтә; үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен балалар бакчасында да ,өйдә дә, урамда да үтәргә тырыша .

-Тәрбияченең сорауларын аңлый һәм җавап бирергә тырыша,уенчыкларның һәм тирә-юньдәге әйберләрнең исемнәрен белә.Шигырьләргә,җырларга,экиятләргә карата кызыксынучанлык күрсәтә.Театральләштерелгән,курчак театры һәм сюжетлы уеннарында катнашырга тырыша.

## 1.6 Икенче кечкенәләр төркеме өчен көндәлек режим № 8 (3-4 яшь).

| Үткәреләсе чаралар | Үткәрү вакыты |
|---|---|
| Кабул итеп алу, тикшерү , саф һавада булу, уеннар , иртәнге гимнастика , индивидуаль эш , балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | 06.00-08.05 |
| Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш. | 08.05-08.40 |
| Уеннар , балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, белем бирү эшчәнлегенә әзерлек (чәрш.08.40-09.00, 09.15-10.00) | 08.40-08.50<br>09.05-09.25 |
| 1 нче белем бирү эшчәнлеге(чәрш.09.00-09.15) | 08.50-9.05 |
| 2 нче белем бирү эшчәнлеге (дүш.09.25-09.40, чәршәмбе- саф һавада физик тәрбия - 10.00-10.15) | 09.15-09.30 |
| Икенче иртәнге аш (дүш.09.45-09.50) | 09.30-09.35 |
| Саф һавага чыгарга әзерлек , саф һавада булу (уеннар, күзәтү, хезмәт) (дүш.09.50-11.30) | 9.35-11.30 |
| Урамнан керү, гигиена процедуралары, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, көндезге ашка әзерлек | 11.30-11.50 |
| Көндезге аш(әбәт) | 11.50-12.20 |
| Гигиена процедуралары, көндезге йокыга әзерлек, көндезге йокы | 12.20-15.00 |
| Йокыдан тору, чыныктыру чаралары, мөстәкыйль эшчәнлек | 15.00-15.20 |
| Төшке аш | 15.20-15.30 |
| Саф һавада булу | 15.30-16.20 |
| Кичке ашка әзерлек , гигиена процедуралары, | 16.20-16.30 |
| Кичке аш | 16.30-17.00 |
| Гигиена процедуралары ,еннар , балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге , саф һавага чыгарга әзерлек, саф һавада йөрү, балаларны өйгә озату | 17.00-18.00 |

Эш программасында эшчәнлекләр тематикасы атналап бүленгән.Атна эчендә төрле комплекслы эш башкарыла.Бу эшне педагоглар, бирелгән таблицага таянып, үзләренчә планлаштыра алалар.

**Бер атнага төп белем бирү эшчәнлекләренең исемлеге:**

атнага 10 белем бирү эшчәнлеге, белем бирү эшчәнлегенең вакыты – 15 минут.

- әйләнә-тирә белән танышу-1

- сөйләм телен үстерү-1
- рәсем – 1
- әвәләү – 1 кисеп ябыштыру-1 -математика-1
- физкультура -3
- музыка – 2.

| **№ 8-төркемнең  комплекты (комплектование группы)** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Төркемнең номеры | Баланың яше | саны | кызлар | малайлар | Төркемнең тулылыгы | Тулылык(с буенча) Фактическ наполняем |
| 8 | 3-4 | 19 | 7 | 12 | 19 | 19 |

# II бүлек

## 2. 1.Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге (Икече кечкенәләр  төркеме)

### 2.1.1. Физик үсеш.

**“Сәләмәтлек” белем бирү өлкәсе.**

«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлекләрен саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту; учреждение төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш торышы үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климатик шартларын һәм ел фасылларыүзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын системалы чыныктыруга, хәрәкәтләрнең төп төрләре формалашуга һәм камилләшүгә шартлар тудыру.Балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту ; гәүдә төзлеген формалаштыру, даими рәвештә организмны чыныктыру, шөгыльләрдә һәм көндәлек эшчәнлек вакытында төп хәрәкәт төрләрен үстерү, камиллләштерү, чисталык күнекмәләре тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Балаларның әйләнә-тирәдә ориентлаша белүләрен камилләштерү. Күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә балаларның катнашуларын хуплау. Балаларда уңай кичерешләр, мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлегендә активлык формалаштыруга булышлык итү.

**Балаларның психик һәм физик сәләмәтлекләрен саклау һәм ныгыту.**

Һава, кояш, судан файдаланып, чыныктыру чаралары комплексын уздыру.

Балаларны бина эчендә җиңел киенеп йөрергә күнектерү. Көндәлек режим буенча саф һавада йөртү. Һәр көн иртәнге гимнастика үткәрү. Һавада йөргәндә хәрәкәтле күмәк уеннарда һәм физик күнегүләрдә катнашырга күнектерү. Физик күнегүләргә кызыксыну уяту, шөгыльләрдән тыш буш вакытларда физкультура җиһазларыннан файдаланырга өйрәтү.

**Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләү.Сәләмәт тормыш нигезләрен формалаштыру.**

Культура-гигиена процедураларының төп алгоритмнары белән таныштыру. Балаларны гигиена процедураларын аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә башкарырга гадәтләндерү. Сабынны дөрес куллану, кулларны, битне, колакларны чиста юу; юынгач коры итеп сөртенү, сөлгене урынына элү, тарак һәм кулъяулык куллану күнекмәләрен формалаштыру. Өстәл янында үз-үзеңне дөрес тотуның иң гади күнекмәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларын,салфетканы дөрес куллану.Ипине вакламаска, азыкны түкми-чәчми ашарга, ризыкны авызны ябып чәйнәргә, ашап туйгач рәхмәт белдерергә күнектерү.

Милли ризыклар: токмачлы аш, шулпалы пилмән, чумар ашы, сөтле чәй һ. б. белән таныштыру. Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау булдыру; яшелчәләр һәм җиләк-җимеш, кеше организмы өчен файдалы сөт ризыклары: каймак, катык, эремчек һ. б. белән таныштыру. Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Үз сәламәтлегеңә һәм якын кешеләреңнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү. Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру.

Балаларны пөхтәлеккә, тышкы кыяфәтләрен тәртиптә тотарга күнектерү.

**“Физик культура” белем бирү өлкәсе.**

“Физик культура” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләрендә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру масксатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Акрынлап катлаулырак кагыйдәле һәм хәрәкәтләр алмашынулы уеннар уйнарга өйрәтү.

**Физик сыйфатларны үстерү.**

Йөреш осталыкларын үстерү.Күнегүләр ясаганда гәүдәне дөрес тоту,әйләнә-тирәдә ориентлаша белергә өйрәтү.Төп хәрәкәтләрне камилләштерү.Шуышу осталыкларын үстерү.Хәрәкәтле уеннарда балаларның хәрәкәт активлыкларын формалаштыру. Шуышу, үрмәләү күнекмәләрен үстерүче уеннарны, тупны ыргыту һәм тотып алу уеннарын хуплау. **“Куркынычсызлык” белем бирү өлкәсе.**

“Куркынычсызлык” белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышының куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. **Тормыш куркынчсызлыгы нигезләрен формалаштыру.**

Балаларны балалар бакчсында үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру.

Тормышта була торган куркыныч чыганаклар(кайнар су, ут, кисә һәм чәнчи торган очлы предметлар, электр приборлары һ. б.) турында күзаллаулар булдыру.Сулыкларда коенганда сак булырга күнектерү.

**Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру.**

Балаларны юлларның машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган өлешләре (тротуар) белән таныштыру; светофорның кызыл, сары һәм яшел төсләренең мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Күрү сигналлары ярдәмендә йөрергә өйрәтү.Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен кирәкле булган ситуация һәм объектларны аерып карап, урам, транспорт чаралары турында170 бербөтен күзаллау формалаштыру.

Хәрәкәт итү чараларының атамалары һәм аларны файдалану максатлары белән таныштыру. Җиңел һәм йөк машиналарының охшаш һәм аермалы якларын табарга, мөһим детальләрен (автомобильдә: кабина, руль, тәгәрмәчләр һ. б.), тору урынын (тәрәзә артында, биек, ерак) әйтә белергә өйрәтү. Хәрәкәт итү чараларының (трамвай, троллейбус, автобус) кайбер охшаш якларына игътибар итәргә, аларны аерым үзенчәлекләре, бурычлары буенча төркемли белергә күнектерү.Транспорт төрләре(җир өсте, су, һава һ. б.)турында беренчел күзаллауларын булдыру.

Тавыш чыганагының (хәрәкәт итә торган транспорт, автомобиль сигналы, светофорның яшел төсе вакытындагы тавыш сигналы һ. б.) урынын билгели белү, төрле яңгырашлы тавышны кабул итү, хәрәкәт итүче самолёт, поезд, трамвай һ. б. ның тавышларын аера белү күнекмәләрен үстерү. Ишетү игътибар-лылыгын үстерү.Өлкәннәр хезмәте (машина йөртүче, ЮХИДИ инспекторы, кондуктор (билет сатучы) турында күзаллау формалаштыру, аларның эш-гамәлләренә һәм эш нәтиҗәләренә игътибар итү. «Автобус», «Трамвай», «Такси» һ.

б. сюжетлы-рольле уеннар үсеше өчен предметлы-уенлы мохит булдыру; балаларга образлы уенчыкларны, аларны алмаштыручы предметларны, уен мохите тудыра торган модульләрне иркен куллану мөмкинлеге бирү.

### 2.1.2. Социаль-шәхси үсеш

**Социальләштерү**белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәббәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. Тирә-юньдәгеләргә карата кызыксыну һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү. Туган телдә ышанычлы аралашу шартлары тудыру. Әйләнә-тирә дөнья, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турындагы төрле мәгълүмат чыганагы буларак, балаларның өлкәннәр белән аралашуга ихтыяҗын хуплау. **Уен эшчәнлегенең үсеше.**

Балаларның бергәләп уйнауларын хуплау. Төрле уеннарга карата кызыксыну уяту. Күңел ятуына карап 2-3 кешенең берләшеп уйнауларына булышу. Уеннар процессында әйләнә-тирәгә кызыксыну уяту.

**Сюжетлы-рольле уенар.**

Сюжетлы-рольле уеннарны, яки шәхси, аерым бер уенны мөстәкыйль оештыруны хуплау.

Балалар арасында роль алу, рольләр бүлешү, уеннарда берләшә белү һәм рольдә аралашу осталыкларын үстерү; җәмәгать транспортында аралашу культурасы белән бәйле рольле репликаларны хуплау..Балаларның инициативалы сөйләмен үстерү, хәрәкәт итү чаралары турында күзаллауларын киңәйтү һәм ачыклау максатыннан, мөстәкыйль карау өчен төрле рәсемле китаплар, реклама буклетлары, техник уенчыклар тупланмасын карарга мөмкинлек бирү; балаларның сорауларын хуплау.Әйләнә-тирәдә гади

закончалыклар һәм бәйләнешләр булуына игътибар итү, мәсәлән, әгәр караңгы икән – ут кабызырга, урамда тайгак икән – кеше үтеп йөри торган җирләрдә ком сибәргә һ. б.

**Хәрәкәтле уеннар**.

Балаларның хәрәкәт активлыкларын үстерү.Уенчык машиналар, арбалар, туплар белән мөстәкыль уйнарга күнектерү. Үрмәләү, шуышу күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтләрне җиңел, оста, җитез итеп башкаруларына ирешү.Балаларның дидактик материал белән булган мөстәкыйль уеннарына шартлар тудыру. Хәрәкәтле уеннар:«Чыпчыклар һәм автомобиль», «Поезд» һ. б. кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү Балаларда хәрәкәтләрне яраштыру, тирә-юньдә ориетлаша һәм уенның кагыйдәләрен үти белү күнекмәләре тәрбияләү.

**Театральләштерелгән уеннар.**

Балаларнытеатральләштерелгән уеннар белән таныштыру.Уеннарны сәхнәләштерү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Игътибар белән күзәтә белү күнекмәләрен ныгыту. Сәнгать иҗатын образлы итеп башкару юлы белән балаларны мавыктыру, шул ук вакытта уенны төрле формалар ярдәмендә сәхнәләштерү процесына тарту.

Персонажларның характерлы гамәлләрен охшатып уйнарга өйрәтү. Балаларны өстәл театры курчакларын йөртү алымнары белән таныштыру.

**Әхлак тәрбиясе нормалары белән таныштыру.**

Өйдә, балалар бакчасында, урамда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Яхшылык һәм начарлык төшенчәләре белән таныштыру.Яшьтәшләрен җәлләү, кочаклау, ярдәм итү омтылышларын хуплау. Кешелеклелек, дуслык, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләүгә булышлык итүче ситуацияләр тудыру. Аралашу әдәбенә өйрәтү.

Балаларда бер-берсенә карата дустанә мөнәсәбәттә булу, яхшы һәм начар гамәлләрне дәрес бәяли белү тәҗрибәсе формалаштыру. Әдәплелеккә өйрәтү: исәнләшү, саубуллашу, ярдәм өчен рәхмәт белдерү күнекмәләрен ныгыту.Үзара дус яшәргә, уенчыклардан, китаплардан уртак файдаланырга, бер-береңә ярдәм итешергә өйрәтү.

**Гаилә, гражданлык төшенчәләрен аңлату, патриотик хисләр тәрбияләү, дөнья берләшмәсенә катнаш булулурын исбатлау.**

**Туган ил**.Балаларны республиканың истәлекле төп бәйрәмнәре белән таныштыру. Балалар бакчасы тормышы, республикадагы, илдәге вакыйгаларга мөнәсәбәтле булу хисетәрбияләү.

Үз милләтенең һәм башка халыкларның йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру.

**Гаилә.**Гаилә әгъзалары (әти-әни, бабай-әби, абый-эне, апа-сеңел), аларның исемнәре, бер-берләрен кайгырту ысуллары турында күзаллаулар формалаштыру; өлкәннәрнең үтенеч һәм йомышларын үтисе, гаилә әгъзалары белән уртак хезмәттә катнашасы килү теләкләрен хуплау. Атаана һәм башка якын кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү. **Балалар бакчасы**. Балалар бакчасындагы хезмәткәрләрнең исемнәре, әтиләренең исемнәре белән танышу. Төркем бүлмәсен тәртиптә тотарга күнектерү. Бина эчендә, мәйданчыкта ориентлаша белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Өлкәннәр хезмәте.**Балаларның өлкәннәр хезмәте,аларның һөнәрләре турындагы белемнәренкиңәйтү.Аларны төзүчеләр,авыл эшчәннәре,транспорт,элемтә,тегү, сәнгать өлкәсендәге хезмәткәрләрнең хезмәте белән таныштыру.Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү. **Хезмәт белем бирү өлкәсе.**

«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Кече фольклор жанрлары ярдәмендә балаларда хезмәт эшчәнлегe турында кайбер күзаллаулар формалаштыру. Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү һәм хезмәт эшчәнлекләре (хуҗалык-көнкүреш хезмәте, табигатьтәге хезмәт) барышында татар халык мәкальләрен файдалану.Әти-әниләрнең балалар аңлый торган һөнәрләре (табиб, сатучы, шофёр, төзүче һ. б.) белән таныштыру. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Мөстәкыйль киенергә, чишенергә өйрәтү.Үзараярдәмләшү тойгысы тәрбияләү.

**Хуҗалык-көнкүреш хезмәте.**

Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта тәртип һәм чисталык сакларга өйрәтү. Өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.

**Табигатьтәге хезмәт.**

Табигать почмагында үсемлекләрне тәрбияләүдә катнашу теләге үстерү. Өлкәннәр ярдәме белән кошларны ашатырга, бүлмә гөлләренә су сибәргә, яфракларның тузанын сөртергә, түтәлдәге үсемлекләргә су сибәргә, яшелчәләрне җыярга, кардан юлларны чистартырга, коелган яфракларны җыярга өйрәтү.

**Хезмәт хәзинәләрен саклый белергә өйрәтү**. Өлкәннәр хезмәтенә уңай караш тәрбияләү. Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлегенә көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру. Таныш һөнәр кешеләренә хөрмәт тәрбияләү эшен дәвам итү.

**Өлкәннәренең хезмәте турында беренчел күзаллау булдыру.** Һәр уңай очракта балаларга таныш һөнәрләр турында сөйләү, аларның хезмәт төрләре һәм хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Таныш һөнәр кешеләренә хөрмәт тәрбияләү эшен дәвам итү.

### 2.1.3. Танып белү-сөйләм үсеше.

**Танып белү өлкәсе**

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл) исемнәрен әйтергә өйрәтү. Әйләнә-тирә (шәһәр яки авылның төп объектлары), янәшәдәге предметлар, аларның билгеләнешләре белән таныштыруны дәвам итү. Кешеләр яши торган йортларның төзелеше, өй кирәк-яраклары турындагы күзаллауларын үстерү.Балалар бакчасында, өйдә була торган вакыйгаларда (бәйрәм иртәләрендә, якын кешеләренең һәм яшьтәшләренең туган көннәре һ. б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә, гаилә бәйрәмнәрендә катнашу һ. б.) актив катнашасы килү теләге уяту.

Үз-үзләрен кунакта, дусларының туган көннәрендә, халык бәйрәмнәрендә, балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Урамда, юлларда, җәмәгать транспортында тәртип кагыйдәләре белән таныштыру.Балаларда ял (бәйрәм) көннәрен кем белән, кайда (циркта, «Кырлай» аттракцион паркында, үзәк мәйданда, шәһәр урамнарында, шәһәрдән читтә) үткәрүләре турында сөйләргә теләк уяту. Вакыйгаларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт чагылышын, алган тәэсирләрен өлкәннәр һәм балалар белән бүлешүгә омтылышларын хуплау. Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар (каен, имән, чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк атучы үлән үсемлекләр (тузганак, үги ана

яфрагы), бүлмә гөлләре (яран, фикус) белән таныштыру. Бөҗәкләр (күбәләк, камка, энә карагы) турындагы күзаллауларын киңәйтү.Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар, аларның үзенчәлекләре белән таныштыру эшен дәвам итү.

Хайваннар дөньясына, барлык тереклек ияләренә, табигатькә карата кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше һәм табигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыллары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына

(салават күпере, агачлардагы бәс, беренче чәчәкләр күренү h. б.га) соклана белү күнекмәләреүстерү. **Танып-белү, тикшерү һәм иҗади эшчәнлекне үстерү**

Тикшерү, кызыксынуны хуплап гади күзәтүләр үткәрү. Төрле ысуллар һәм тәҗрибәләр ярдәмендә предметны тикшерү.Катлаулы булмаган төзелешләрне анализлау. Конструктив осталыкларын тормышка ашыру.

Кубик, кирпеч белән танышу.Яңа төзелешләр-корылмалар уйлап чыгару сәләтен үстерү. Яхшы килеп чыккан төзелешкә-корылмага шатлану хисе уяту.Балаларны уйнаганнан соң төзелеш материалларын җыештырып куярга күнектерү.

**Дөнья картинасын үзләштерү, белем дәрәҗәсен үстерү.** Балаларның тирә-юньдәге предметлар һәм аларның кулланышы турындагы белемнәрен киңәйтү. Предметларның төсен, зурлыгын, балага аңлату. Яхшы таныш әйберләрне төркемнәргә аерырга өйрәтү.

**Табигать күренешләре белән таныштыру**.

Әйберләрнең өлеш-кисәкләрен атарга өйрәтү. Гади бәйләнешләрне аңлата башлау,тормыштагы һәм табигатьтәге(кояш чыкса-кыздыра,яңгыр яуса-пычрак була).Гаилә членнары хезмәте белән кызыксына башлау һәм аларның эшен атый белү(әни мәктәптә укыта-укытучы).Өй кирәк яраклары белән таныштыру.Берсен икенчесеннән аера һәм исемнәрен әйтә белергә өйрәтү.Әйберләрне төсләре,формалары,зурлыклары белән төркемли белү.

Агачлар,куаклар,үләннәр белән таныштыру,балаларда табигать белән кызыксыну уяту,аңа сакчыл караш тәрбияләү.Үсемлекләрне тәрбияләп үстерүдә өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.Үсемлекләр тормышындагы кайбер үзенчәлекләр(чәчәк ату,җимеш бирү)белән таныштыру(бакчада үсә торган 2-3 үсемлек үрнәгендә).Тышкы билгеләре буенча аларны таный,исемнәрен әйтә һәм бер-берсеннән аера белергә(агач биек,куак һәм үләннәр тәбәнәк,агачның яфраклары яшел һәм бик күп)өйрәтүне дәвам иттерү.

Балаларны һава торышы белән таныштыру, ел фасылларының характерлы үзенчәлекләре белән таныштыра башлау ( яфраклар коела, кар ява, гөрләвекләр ага h.б.)

Йорт хайваннары,кыргый хайваннар һәм аларның балалары белән танышу,алар турында турында башлангыч төшенчәләр бирү. Аларның өлешләрен әйтә белү,сөйләмдә файдалану.Хайваннарны ярату,аларны саклау һәм тәрбияләүгә өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.Кайбер бөҗәкләр ,кошлар белән таныштыру.

**Сөйләм үстерү мохите.**

**«Аралашу» белем бирү өлкәсе.**

«Аралашу» белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чараларын үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәмбелем бирү бурычларын билгели.

Баланы туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, аралашырга өйрәтү; күргәннәре турында күзаллап сөйләргә генә түгел, тормышында булган вакыйгалар, башкарган эш-

гамәлләре, үзен кызыксындырган күренеш һәм предметлар, туган як табигате объектлары турында да сөйләргә күнектерү.Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. Үз фикерләрен әйтү, үтенеч һәм тәкъдимнәр белән өлкәннәргә мөрәҗәгать итү омтылышларын хуплау.Таныш булган татар (рус) халык әкиятләреннән өзекләр, шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү; 2–
3 җөмләдән торган хикәяләр төзергә өйрәтү. Җөмләдәге сүзләрне дөрес бәйләр өчен, кушымчаларны дөрес файдаланырга өйрәтү.Балаларның уен барышында үзара мөнәсәбәтләрен (уендагы үзләренең эш-гамәлләре турында сөйлиләр, уенчыклар, аларны алмаштыручы предметларны сүзләр белән атыйлар) җайга салырга булышу. Балаларның сөйләмен барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү өчен кирәкле сүзләр белән баету.Туган телдәге авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, аваз культурасы тәрбияләү. Таныш өлкән кешеләр һәм үз яшьтәшләре белән төрле йомышлар кушу аша аралашырга ярдәм итү.Төркем бүлмәсенә кергән кешеләргә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

Тормыш-көнкүрештә, уеннар вакытында бердәм гамәлләр башкарырга, бер-берләре белән элемтәләрен көйләргә ярдәм итү.

Тирә-юньдәге предметлар, күренешләр турында белемнәрен, күзаллауларын киңәйтү максатыннан, балаларга мөстәкыйль карау өчен рәсемле китаплар, уенчыклар, реклама буклетлары тәкъдим итү.

Тәрбияченең балаларга кызыклы вакыйгалар, хайваннарның шуклыклыры, саф һавадагы кызыклы уеннар турында хикәяләвен тыңларга күнектерү.Көндәлек тормышта,уен вакытында башкаларга карата ягымлы мөгалләмә булдыру.Сөйләшү чаралары ярдәмендә бәхәсле сорауларны,конфликтларны уңай хәл итәргә өйрәтү.

**Сүз байлыгын үстерү.**

Әйләнә-тирә турындагы белемнәре арту нәтиҗәсендә сүзлек запасын арттыру һәм активлаштыру.

Өс-баш, аяк киеменең, савыт-саба, йорт җиһазлары, транспорт төрләренең исемнәренә, аларның кулланышына аныклык кертү.

Предметларның төп өлешләрен, аерым детальләрен, сыйфатларын, нинди материалдан эшләнүен, аларга хас булган сыйфатларын, кайда урнашуын әйтә белергә өйрәтү. Кулланышлары охшаш булган әйберләр арасындагы аерманы күрә , аңлый белергә өйрәтү. Тәүлекнең өлешләрен әйтә белү. Кыргый һәм йорт хайваннары яшәү рәвешен әөрәтү. Яшелчә һәм җиләк-җимешләрне тасвирлап сөйләргә өйрәтү.

Исемнәрне сыйфатлар белән бәйләргә өйрәтү;мәгънәдәш сүзләр,капма-каршы мәгънәле сүзләр куллану күнекмәләре бирү. **Авазларны дөрес әйтә белү.**

Балаларны ашыкмыйча,аңлаешлы итеп сөйләргә күнектерү.Сузык һәм тартык авазларны ,аваз ияртемнәрен(бак-бак,тик-так,му-му),аерым сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү буенча, авазларга охшатып ясалган сүзләрне(аваз ияртемнәрен төрле тизлектә,шыпырт кына яки кычкырып)әйтү буенча күнегүләр башкару.

**Сөйләмнең грамматик төзелеше.**

Балалар актив куллана торган сүзләрне ишәйтү,сөйләмнәрнең грамматик төзелешен камилләштерү,яшьтәшләре һәм олылар белән сөйләшә башлауларына ирешү,олыларның һәм яшьтәшләренең сөйләвен тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтү. Исемнәрне һәм сыйфатларны фигыльләр белән  яраштырып әйтергә,гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйләргә гадәтләндерү(Ралина шаяра,мин шаярмыйм,Тимур бүген бакчага килмәде).Җөмләләрне грамматик яктан дөрес итеп төзи белүләрен күзәтү һәм бу эштә аларга ярдәм итү. Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның төп шарты –

тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү .**

Сөйләмнең ике формасын - диалоглы һәм монологлы сөйләм үстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора. Балаларның диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү юнәлешендә эшләү:иптәшләре белән үзара тыныч,ягымлы итеп сөйләшә белергә,башкалар сөйләгәнне игътибар белән тыңларга өйрәтү. Предметлар, рәсемнәр караганда, тере объектларны, төзелеш эшләрен күзәткәндә, мультфильмнар караганнан соң әңгәмәләргә тарту. Педагог белән кара-каршы сөйләшергә өйрәтү(диалог).Үзе күргән вакыйгалар турында фикерләрен өлкәннәр белән уртаклашасы килү теләге булдыру.Гаиләдә, төркем бүлмәсендә өлкәннәргә, иптәшләренә “рәхмәт”, “исәнмесез”, “сау булыгыз”, “тыныч йокы” кебек сүзләр әйтү зарурлыгын төшендерү. Бер-берсе белән яхшы мөнәсәбәттә булырга ярдәм итү.

**«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе.**

«Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Көчле хис-кичерешләр чыганагы булган китапка һәм өлкәннәр белән әдәпле аралашуга кызыксыну формалаштыру.Яшьтәшләре белән бергәләп тәрбияченең сәнгатьле уку яки сөйләмен тыңлау күнекмәләре булдыру.Татар халык әкиятләрендә, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәби әсәрләрендә вакыйгалар барышын күрсәтмәлелек (уенчыклар, рәсемнәр, хәрәкәтләр) ярдәмендә күзәтергә, аларның эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишарәләр белән белдерергә өйрәтү. Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, персонажларга үз мөнәсәбәтен белдерергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү. Әдәби әсәрләргә карата хисси кичерешләр булдыру, әдәби сүзгә кызыксыну уяту. Китаптагы иллюстрацияләрне караганда, әдәби әсәр геройларын һәм аларның гамәлләрен танырга булышу. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (юаткычлар, әйтемнәр, бармак уеннары) белән таныштыру. Кече фольклор формаларын көндәлек тормышта куллануны хуплау. Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар.

Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, “куян булып сикерәләр”, “кошлар булып очалар”, җим чүплиләр”, “аю кебек алпан-тилпән йөриләр”, “әтәч булып кычкыралар” һ.б. Бу уеннарда

музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.
Нәниләр белән эшләгәндә “Җанлы картиналар” куллану зур урын алып тора. “Җанлы картиналар” - тышкы кыяфәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игътибарын җәлеп итәләр. Алар эчтәлеге буенча ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын кыскартырга яки арттырырга, яңа элементлар кертергә мөмкин. “Җанлы картиналар”ны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар, кибет һ.б. белән таныштыру.
Балаларның игтибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда балалар эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар: “яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар”, “кер юалар, чайкыйлар, сыгалар”, “кояшны сәламлиләр”, “кояш нурлары ясыйлар” һ.б.
Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә күрсәтелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль. Балаларны активлаштыру балаларның җавапларын конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максаты белән эшләнә.
Тәрбияче балаларга гомуми сораулар белән мөрәҗәгать итә, барлык балаларга да бирелгән сорауны кечкенә бала үзенә бирелгән дип кабул итми, шуңа күрә тәрбиячегә соравын конкретлаштырырга кирәк (- Балалар, алма нинди төстә? – Әмир, алма нинди төстә? – Гүзәл, алма нинди төстә? - Балалар, минем янга килегез әле. – Марат, син дә кил әле. –Алсу, син дә кил.).

### 2.1.4.Нәфис-нәфасәти үсеш.

«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

**Сәнгать белән танышу.**
Балаларны сынлы сәнгать әсәрләрен кабул итәргә, аларны әйләнә-тирә чынбарлыгыннан аерып ала белергә әзерләү. Сәнгатьнең төрле төрләрендәге сәнгати чаралар (төс, аваз,

форма, хәрәкәт, ишарәләр) белән таныштыру, төрле сәнгать төрләрен сәнгать образы аша аерырга өйрәтү.

Балаларны беренче тапкыр курчак театрына, халык җәүһәрләренә һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә, әдәбиятка, музыкаль әсәрләрне тыңлау һәм башкаруга кызыксыну тәрбияләү. Табигатьтә сезонлы үзгәрешләрнең, әйләнә-тирәдәге предметларның(төсе,формасы, зурлыгы: өй, палас, савыт-саба) матурлыгын күрә белергә өйрәтү.

**Нәфис-нәфасәти үсеш мохите.**

Балаларда төркемнең җиһазланышы һәм бизәлешенә (матур, уңайлы йорт җиһазлары, яңа уенчыклар, китап почмагында тезеп куелган төсле рәсемле китаплар) шатлык хисләре уяту. Үзләренә уңайлы һәм матур булсын өчен төркемдә чисталык һәм тәртип булдыруга омтылыш тәрбияләү.Игътибарларын үсемлекләргә, аларның төрлелегенә һәм матурлыгына юнәлтү.

**Сурәтләү эшчәнлеге.**

Нәфәсәти зиһенгә алуны үстерү, балаларның игътибарын әйләнә-тирәдәге предметларның матурлыгына юнәлтү(үсемлекләр, хайваннар),шатлык хисләре уяту.

Сурәтләү эшчәнлеге шөгыльләренә кызыксыну тудыру. Табигать матурлыгына, сәнгать әсәрләренәуңай эмоциональ караш тәрбияләү.Рәсем, әвәләү эшчәнлегендә мәстәкыйль, шулай ук коллектив композицияләр иҗат итәргә өйрәтү.Балаларда,барлык эшләрне караганнан соң, ирешелгән нәтиҗәләргә карап, шатлану тойгысы уяту.

**Рәсем**

Карандаш, фломастер, пумаланы мускулларны киеренкеләндермичә һәм бармакларны каты кысмыйча, дөрес итеп тотарга өйрәтү, рәсем ясаганда карандаш һәм пумала тоткан кулларның иркен хәрәкәтләнүенә ирешү. Пумаланы буяуга дөрес итеп манарга өйрәтү. Пумаланы буяулы банкага пөхтә итеп манарга, артык буяуны банка кырыена ышкып төшерергә, башка төскә манганчы, пумаланы юарга. Юылган пумаланы йомшак чүпрәк яки кәгазь салфеткага сөртеп киптерергә гадәтләндерү.

Балаларны «орнамент» төшенчәсе белән таныштыру. Татар орнаментында оста итеп чагылдырылган чын чәчәк-үсемлек мотивларын карау. Бизәкнең өлешләрен аера белергә өйрәтү.

Төс һәм төсмерләрне тану, төсләрне ныгыту.Уенчык силуэтларынһәм төрле предметларны бизәргә өйрәтү. Сызык, штрих, буялыш(мазки), тимгел-тимгел тапларны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү(агач яфраклары коела, яңгыр ява, җиргә ап-ак кар ява, “тып-тып-тып итә эре-эре тамчылар...”)

Төрле юнәлештә сызыклар сызарга, аларны кисештерергә(тасмалар, юллар, койма) өйрәтү. Төрле формалы(түгәрәк), төрле форма һәм сызыклардан торган предметларны сурәтләргә(аумас курчак,кар бабай, чеби, арба, вагон) өйрәтү.

**Әвәләү.**

Әвәләп ясау белән кызыксынуны үстерү.Пластилин белән танышу,аның үзлекләре һәм әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту.Зур кисәктән кечерәк кисәкләр өзеп яки чеметеп алу, аларны бармаклар ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтү, өлешләрне тоташтыру (чәчәк, гранат, миләш җимешләре); янчелгән шарның өстен шомарту, җиңел

генә тарттырып, кырыйларын чеметкәләп чыгу – бөрү (гөбәдия, вак бәлеш һ. б.) күнекмәләре формалаштыру. Махсус таякчык (стека) ярдәмендә ике яки дүрт кисәккә бүлеп (бәлеш кисәкләре), килеп чыккан формаларны үзгәртергә тырышуларын хуплау.
Яңа форма барлыкка китерү өчен, шарның уртасын яньчеп, чокыр ясау ысулын куллану. Махсус таякчыкны файдалану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган әйберләргә шушы таякчык ярдәмендә милли бизәкләр төшерергә омтылуларын хуплау.Пластилин белән пөхтә итеп эшләргә күнектерү,әвәләгән предметлар һәм кисәкләрне әвәләү тактасына кую.Әвәләп ясалган әйберләрне күмәк композициягә (тәлинкәдәге сый, чәй сервизы һ. б.) берләштерү. Уртак эш нәтиҗәсен күреп шатлану хисләре уяту.
**Кисеп ябыштыру.**Балаларны кисеп-ябыштыру сәнгатенә тарту, бу эшчәнлек төренә кызыксыну уяту. Орнаментның алдан ук әзерләнгән формаларын кәгазь кисәгендә билгеле бер тәртиптә тезеп куярга - уртага, квадрат, түгәрәк кырыйларына урнаштырырга өйрәтү, күмәк композицияләр иҗат итү күнекмәләрен үстерү.

**Музыкаль тәрбия бирү.**
Зур булмаган җырларны,музыка коралларында башкарыла торган музыкаль әсәрләрне тыңлауга кызыксыну уяту.Җырларга өйрәтүне һәм ритмлы хәрәкәтләр ясарга өйрәтүне дәвам итү.

**Музыка тыңлау.**Тыныч һәм дәртле җырларны ,төрле характердагы музыкаль әсәрләрне игътибар белән тыңларга күнектерү.Җырда кем яисә нәрсә турында җырлаганын аңларга өйрәтү.Балаларны халык һәм классик музыка белән таныштыру; -әч музыкаль жанр белән таныштыру (җыр, бию, марш) күңелле һәм моңсу көйләрне аерырга өйрәтү; -музыкаль әсәрләрне ахыргача тыңлый белергә өйрәтү; -югарылыклары буенча музыкаль авазларны аерырга өйрәтү; -музыкаль уен кораллары тавышын танып аерырга өйрәтү (барабан, бубен, металлофон, шарманка, чукеч, шалтыравык) **Җырлау.** Җырда кабатланган музыкаль фразаларны тәрбиячегә кушылып җырлый белү күнекмәләре булдыру өстендә эшләү.Хис белән җырларга өйрәтү;музыкаль ритмик хәрәкәтләр.

**Музыка ритмына хәрәкәтләр.**Характеры ачык чагылган музыкага туры килә торган хәрәкәтләр ясарга,хәрәкәтләрне музыка белән бергә башларга һәм тәмамларга өйрәтү.

## 2.2. Программаның милли-төбәк компоненты.

Шәхескә белем бирү, аны тәрбияләү һәм тормышка әзерләүдә күп факторлар катнаша: гаилә, тирә-юнь, урам, табигать һәм шулар белән белән бәррәттән милли-региональ үзенчәлекләр. Һәр халык, Һәр милләт үзенеңрухи байлыгын үзенчәлекле шартларда, үзенчәлекле юллар һәм алымнар белән туплаган. Аларның һәрберсе дөнья мәдәниятенә үзеннән сизелерлек өлеш кертә, баета. Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомумкешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының , үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү. Шуннан чыгып, программага милли-региональ компонент өстәлгән. Милли төбәк өлеше билгеле бер төбәкнең мәгариф өлкәсендә мәнфәгатьләрен, туган як мәдәниятен, гореф-гадәтләрне, тел һәм

әдәбиятны, тарих, география һ.б. үзенчәлекләрне белү зарурлыгын билгели. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004) Татарстан халыкларын, аларның мәдәниятен һәм телләрен саклау, һәръяклап үстерүне, җәмгыятнең социаль-икътисади, рухи-әхлакый үсүендә һәр милләтнең иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм күркәм традицияләрен тулысынча файдалануны күздә тота. Тәрбия белем бирү программасында милли-төбәк компоненты кертелүе әлеге законны гамәлгә ашыруда зур ярдәмлек булып тора.

**2.2.1.Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып икенче кечкенәләр төркемендә тәрбия һәм укыту бурычлары** -Туган якның кошларына, хайваннарына, үсемлекләренә карата сакчыл һәм кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү.

- Балаларның сәләмәтлекләрен ныгытырга дәвам итү.
- Өлкәннәрнең хезмәтенә кызыксыну уяту; хезмәткә карата уңай караш тәрбияләү, һәр хезмәт иясен хөрмәтләргә өйрәтү.
- Балаларның сөйләмнәрен үстерү.

### 2.3. Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып юнәлеш эчтәлеге

| Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып юнәлеш эчтәлеге | | |
|---|---|---|
| 1 | Сәламәтлек | Тойгы органнары белән танышу, аера белү осталыкларнын үстерү(күз, авыз, борын, колак).<br>Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау булдыру,аңлату балаларга. Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Үз сәламәтлегенә һәм якын кешеләрнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү.<br>Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру. |
| 2 | Физик культура | Татар халкының милли уеннарына карата кызыксыну уяту, уеннарның кагыйдәләрен ныгыту. |
| 3 | Социальләштерү | Халык уеннарын уйнау процессында зурлар һәм яшьтәшләре арасында дуслык мөнәсәбәтләре формалаштыру. |
| 4 | Хезмәт | Сөйләмдә үз халкының кечкенә иҗат формаларын кулланып үз-үзләренә хезмәт күрсәтү, хуҗалык-көнкүреш хезмәтен үзләштерү, |
| 5 | Куркынычсызлык | Зебра, светофор һәм юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.<br>Тормышта була торган куркыныч чыганаклар турында беренчел күзаллаулар булдыру.<br>Кайбер үсемлекләр, йорт һәм кыргый хайваннар турында күзаллау формалаштыру. |

| | | |
|---|---|---|
| 6 | Матур әдәбият белән таныштыру | Татар фольклорының үрнәкләре белән таныштыру: әкиятләр, бармак уеннары, һ.б. Әдәби әсәрләрнең мәгънәсенә дөрес төшендерү.<br>Эстетик хисләр тәрбияләү.<br>Әкиятләр, шигырьләр тыңлый белү осталыкларын булдыру; татар фольклорының гүзәл үрнәкләре белән таныштыру. |
| 7 | Танып белү | Милли кием үрнәкләрен кулланып сенсор культураны үстерү. .<br>Яр Чаллы- туган шәһәрләре турында белемнәрен баету, туган як табигате күренешләренә кызыксыну уяту. |
| 8 | Музыка | Татар халкының милли көйләренә карата кызыксыну уяту; төп өч жанр төшенчәләрен ныгыту: җыр, бию, милли репертуарга нигезләнгән марш, әйлән-бәйлән халык уеннарын куллану. |
| 9 | Иҗади сәнгать | Татарларның декоратив-ясалма сәнгатенә кызыксыну формалаштыру; татар орнаменты белән әйберләрне бизәргә өйрәтү; иҗади сәнгать эшчәнлегендә “Яфрак”.<br>“Ләлә” бизәкләрен куллану. |
| 10 | Коммуникация | Сөйләмнең бөтен компонентларын үстерү.<br>Туган телнең сөйләм нормалары белән гамәли ия булу. |
| | | Туган телдә өлкәннәр белән ирекле аралашу. |

## 2.4. Комплекслы-тематик планнар
## Икенче кече яштәгеләр төркемендә математик күзаллаулар үстерү буенча перспектив эш планы

### СЕНТЯБРЬ

**1.** Шар, куб.

**2**.Зур-кечкенә.

### ОКТЯБРЬ

**1. Бер, күп, аз.**

2. Предметларның бертөрле һәм төрле-төрле билгеләре. Төркемнән бер предметны аеру.

3.Предметлар төркеме төзү, төркемнән бер предметны аеру.

**4.** Түгәрәк, квадрат.

.

## НОЯБРЬ

1.Балаларның яшь үзенчәлекләрен һәм программа материалын ничек үзләштерүләрен исәпкә алып эшне ирекле планлаштыру.

2. Бер, күп, берәү дә юк.

3.Озын-кыска, озынрак-кыскарак.

4.Бер-күп.

## ДЕКАБРЬ

1.. Күп, никадәр-шулкадәр, бертигез.

2. Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр.

3.. Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр.

4. Киң-тар, киңрәк-таррак.

## ГЫЙНВАР

1-2 Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру.

3. Өчпочмак.

4 Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр.

## ФЕВРАЛЬ

1 Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр.

**2.**. Биек-тәбәнәк, биегрәк-тәбәнәгрәк.

3. Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру.

**4.**. Күп -аз, никадәр-шулкадәр.

## МАРТ

1.Күп-аз, никадәр-шулкадәр.

2. Күбрәк-азрак, никадәр-шулкадәр.

3 — 4 Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру.

## АПРЕЛЬ

**1.** Өстенә, астына, эченә.
**2.** Тою органнары ярдәмендә күплекләрне кабул итү.
**3.** Тою органнары ярдәмендә күплекләрне кабул итү.
**4.** Алда-артта, өстә-аста, сулда-уңда.

**МАЙ**

1. Геометрик фигуралар.

2. Геометрик фигуралардан (түгәрәк, квадрат, өчпочмак) рәсемнәр төзү.

3-4 нче занятие Программа материалын үзләштерүне һәм конкрет яшь төркеменең үзенчәлекләрен исәпкә алып эшне ирекле планлаштыру.

**ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕНДӘ РЭСЕМ ЯСАУ ШӨГЫЛЕНЕҢ ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЫ**

1 Әвәләү: «Әвәләргә өйрәнәбез»
2. Рәсем: «Яңгыр»
3.Төзү: «Миябикәгә сукмак»
4. Әвәләү:«Аюга күчтәнәч»
5.Рәсем: «Тылсымлы таякчык»
6. Кисеп ябыштыру: «Чебиләр очен койма»
7. Әвәләү: «Тылсымлы таякчык»
8. Рәсем: «Сукмак буйлап»
9.Төзү: «Йорт хай-ваннары өчен киртә»
10. Әвәләү «Клиндер»
11. Рәсем: «Тесле тасмалар», «Филимонов уенчыгы»
12. Кисеп ябыштыру: «Парк сукмакларында керпе эзләре»
13. Әвәләү: «Керпе өчен алмалар»
14. Рәсем: «Курчакның итәген бизибез»
15. Төзү: «Манара»
16. Әвәләү: «Пирамидка»
17. Рәсем: «Туплар тәгәриләр»
18. Кисеп ябыштыру: «Аминегә ярдәм итәбез»
19. Әвәләү: «Алмалар һәм җиләкләр»
20. Рәсем: «Аю баласына бизәкле чына-як»
21.Төзү:«Уенчыклар өчен тартма»
22.Әвәләү: «Тиен очен чикләук»
23.Рәсем: «Көзге яфраклар», «Көз»
24.Кисеп ябыштыру: «Миләш мәрҗәне”
25. Әвәләү:«Әниемәкүчтәнәч»
26.Рәсем:«Күңеллетүгәрәкләр»
27.Төзү:«Тиремкәй очен капка»

28.Әвәләү:«Очкычлар аэродромда»
29. Рәсем:«Тимер юлы»
30.Кисен ябыштыру: «Акбайга җылы келәм»
31.Әвәләү: «Әбием өчен касә»
32. Рәсем: «Агач үсте»
33.Төзү:«Койма һәм капка»
34.Әвәләү: «Ният буенча әвәләү»
35.Рәсем: «Кар, кар ява»
36. Кисеп ябыштыру: «Матур шарлар»
37.Әвәләү: «Яшел чыршы»
38. Рәсем: «Кыш»
39.Төзү:«Урындык»
40. Әвәләү: «Кар бабай»
41.Рәсем: « Бизәлгән чыршы»
42.Кисеп ябыштыру: «Кар бабай һәм чыршы»
43.Әвәләү: «Ныгытма корабыз» (күмәк эш)
44.Рәсем: «Минем бияляем»
45.Төзү: «Өстәл»
46.Әвәләү: «Аумас курчак»
47.Рәсем: «Чыршы урманда үсә»
48.Кисеп ябыштыру: «Бәйрәм үремнәре»
49.Әвәләү: «Теләгән уен-чыкны әвәләү»
50.Рәсем: «Күңеле төшмәс курчак»
51.Кисеп ябыштыру: «Матур тастымал»
52.Әвәләү«Куян — озын колак, кысык куз, кыска койрык»
53.Рәсем: «Кышкы ак көн»
54.Төзү: «Алсу исемле курчакка кәнәфи»
55.Әвәләү: «Куянны сыйлыйбыз»
56.Рәсем «Куянны рәнҗеттеләр”
57.Кисеп ябыштыру: «Йорт төзибез»
58.Әвәләү: «Зур һәм кечкенә очкычлар»
59.Рәсем:«Дымкауенчыклары»
60.Төзү: «Бозлы йорт»
65.Рәсем: «Кояш, кояш, кояш, чык»
66.Төзү: «Гараж»
67.Әвәләү: «Әниемә күчтәнәч»
68. Рәсем: «Яз килде»
69.Кисеп ябыштыру: «Әниемә бүләккә умыр-зая чәчәге»
70.Әвәләү:«Мин — куңелле чыпчык»
71.Рәсем:«Болында тузганаклар»
72. Төзү: «Карават»
73.Әвәләү: «Чеби»
74.Рәсем: «Куянга булышабыз»
75.Кисеп ябыштыру: «Нурлы кояш»
76. Әвәләү: «Ният буенча әвәләу»

77. Рәсем:  «Матур әләм»
78.Төзү: «Арба»
79.Әвәләү: «Аюларның савыт-сабалары» (күмәк эш)
80.Рәсем  «Уенчыклар арбасы»
81. Кисеп ябыштыру: «Машина»
82.Әвәләү: «Озын елан»
83.Рәсем:«Әкиятләрдән  таныш хайван-нар»
84.Төзү: «Баскыч»
85.Әвәләү: «Кошлар»
86.Рәсем: «Могҗиза-агачы» (Күмәк эш)
87.Кисеп ябыштыру:«Паровоз»
88.Әвәләү: «Машина»
89.Рәсем: «Чебиләр»
90.Төзү: «Эт оясы»
91.Әвәләү:«Әкәм-төкәм. Әкәм-төкәм мөгезеңне күрсәт»
92.Рәсем:«Мимоза чәчәге»
93.Кисеп ябыштыру: «Тиздән җәй җитә»
94. Әвәләү: «Корт» («Гусеница»)
95. Рәсем «Камка» («Божьи коровки на лужайке»)
96.Төзү:«Безнең шәһәр урамы» (күмәк шөгыль)
97.Әвәләү: «Нәрсә ошый шуны әвәлә»
98.Рәсем:«Җәй, җәй, җәй килә»
99.Кисеп ябыштыру: «Үләндә кем яши»
100.Әвәләү: «Кырыгаяк»
101.Рәсем: «Сабантуйга яулык»
102.Төзү:«Күпер»

## Танып белү өлкәсе

1.Кояш чык!
2.Йомшаккай әзерләгән  сюрприз
3.Манара
4.Куян үстергән кишер һзм помидор
5. Сары, кызыл яфраклар
6. Кунак каршылыйбыз
7. Мин – “КамАЗ” оныгы**.**

8. Тылсымлы шкатулка.

.

9..Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз
“Чанада шуабыз” картинасын карау
Җимлек янында.

.

Ватанны

саклаучылар көне

Минем әнием

Тере һәм уенчык кошларны карау

Урамда яз

“Кәҗә һәм

кәҗә

бәтиләре”

картинасын карау

Тузганак чәчәген

карау

| Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | Кояш, чык! | 1) җәй турында күзаллауларга нигез салу, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү; 2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен; күз алдына китерә, хыяллана белүләрен; вак моториканы, рәсем ясау күнекмәсен, иҗади сәләтләрен үстерү; 3) балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү |
| | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1) агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү; 2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү; |
| | Манара | 1) балаларны төрле зур лыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү. 2) предметның төсен, фор масын, зурлыгын атый белүләренә ирешү; 3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | Куян үстергән кишер һәм помидор | 1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ны гыту; 2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| | Яшелчәләр | 1) балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турындагы күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнә рен ныгыту; 2) яшелчәләрне (кыяр, шал кан) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белергә өйрәтүне дәвам итү; игътибар, аңга алу, диалогик сөйләм, сенсорик сәләтләрен үстерү; 3) сорауларга җавап бирү теләге тудыру; табигать белән кызыксыну тәрби |
| | Сары, кызыл яфраклар | 1) балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълү мат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яф ракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен |

| | | |
|---|---|---|
| | | үстерү; көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү |
| Мин һәм минем гаиләм | Кунак каршылыйбыз | 1) савыт-сабаның аерым предметлары, аларның ку лланылышы турында беле мнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү |
| Минем йортым, минем шәһәрем | Мин – «КамАЗ» оныгы | 1) балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган «КамАЗ» машинасы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү; 2) аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүз ләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү;<br>«КамАЗ» машиналары белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) туган шәһәр, «КамАЗ» эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. |
| Яңа ел бәйрәме | Тылсымлы шкатулка. | 1) балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк тәрбияләү; 2) балаларны чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләргә өйрәтү, диалогик сөйләмнәрен үстерү, со рауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерергә<br>өйрәтә башлау; |

| | | |
|---|---|---|
| | Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз | 1) балаларның кышкы та бигатьнең характерлы үзен чәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, тикшеренүләр бары шында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазларның артикуляциясен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, |
| | | танып белү активлыкларын формалаштыру; |
| Кыш | «Чанада шуабыз»н рәсеме карау | 1) балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлеген аңларга, эч тәлеге буенча сорауларга җа вап бирергә өйрәтүне дәвам итү; 2) диалогик сөйләмнәрен; күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә- образлы фикерләүләрен үс терү; 3) кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү. |
| | Җимлек янында. | 1) кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту; 2) аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын үстерү; |
| Ватанны саклаучылар көне | Ватанны саклаучылар көне | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үс терү; |
| Сигезенче Март | Минем әнием | 1) әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү; 3) балаларда пөхтәлек, әни ләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү. |
| Халык җәүһәрләре | Тере һәм уенчык ы кошларн карау | 1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчык кош – дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту; 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү; 3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| Яз | Урамда яз | 1) балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау бары шында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү; 3) язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү, табигатьтә барган үзгә решләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту |

| | | |
|---|---|---|
| Җәй | «Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре рәсемен карау | »1) балаларны тәрбияче яр дәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга, аның турында сөйләргә өйрәтү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; 2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөй ләмен, дуслык турында күзаллауларын үстерү; 3) тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү; хайваннарга карата кайгыртучанлык тәр бияләү |
| | Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү; 2) үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту; хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; 3) үсемлекләр белән кызык сыну, эстетик хисләр тәрбияләү. |

## III бүлек

### 3.1. Балаларның гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планнаштырылган нәтиҗәләр.

**Интегратив сыйфат “Эмоциональ ярдәмчел “**

Тирә-юньдәгеләргә игелеклелек,мәрхәмәтлелек күрсәтә белә. Якыннарының һәм иптәшләренең эмоцияләренә җавап бирә. Үзенең иптәшен кызгана, аңа ярдәм итә.

Драматизация уеннарын, курчак театрларын бик теләп, кызыксынып карый. Яңа әкият, хикәя, шигырьләрне тыңлый. Әкият персонажлары белән кызыксына.

Рәсем сәнгате белән кызыксына. Тирә-юньдәге матурлыкны (уенчыклар), табигатьтәге матурлыкны күрә, матурлыкны күреп шатлана белә. Әвәләү, рәсем эшчәнлегендә гади предметларны күрсәтә белә.Үз яшенә кагылышлы музыкаль әсәрләрне тыңлый. Күңелле һәм ямансу көйләрне аера.Алган тойгыларын сөйләмдә, нәтиҗәле эшчәнлектә күрсәтә белә.

**Интегратив сыйфат ”Өлкәннәр һәм иптәшләре белән аралашу”**

Көнкүрештә, ирекле уеннар вакытында иптәшләре белән узара сөйләшеп уйный белә.Иптәшләре белән төркемнәргә бүленеп уеннар оештырып уйный.Үзенең хис-тойгылары белән уртаклаша.

Проблемалы вакыйгалар килеп чыкса өлкәннәргә мөрәҗәгать итә. Өлкәннәрнең искәрмәсен һәм әйткәнен тыңлый бел

**Интегратив сыйфат ”Интеллектуаль бурычларны, проблемаларны хәл итәргә сәләтле”**

Үзлектән элементар йомышларны үтәргә омтыла. Үсемлекләр, хайваннарны тәрбияләүдә, мәйданчыкны тәртипкә китерүдә үзенең өлешен

кертә.Теге яки бу уен өчен кирәкбулган предметларны үзлектән таба, уен җиһазларын өсти белә.Үзе уйлап чыгарып төрле төзелешләр ясый. Үзен уен, нәфәсәти эшчәнлек (худ.деят-ть) белән мавыктыра ала.

**Интегратив сыйфат ”Үзе, гаиләсе, җәмгыять, дәүләт, табигать турында гади кузаллаулар.**

Үзе турында гади кузаллауларны белә: исемен.Үзенең гаилә әгъзаларын белә, исемнәрен әйтә.Берникадәр һөнәр белән таныш ( табиб)

**Интегратив эшчәнлек ”Уку эшчәнлеге белән билгеләнгән универсаль алшартлар”**

Балалар бакчасында, өйдә гади тәртип,тәрбия кагыйдәләрен үти.Зур булмаган кыенлыкларны җиңеп , үзлектән кушылган йомышны башкара.Кыенлыклар туса ярдәмгә чакыра белә.Тәрбиячене тыңлый, бирелгән сорауны аңлый белә. Өлкәннәр сөйләгәндә бүлдерми.Китаплар һәм андагы рәсемнәр белән кызыксына.

**Интегратив сыйфат ”Кызыксынучан, актив”**

Төрле төр уеннар, бергәләп уйнауда кызыксынучанлык күрсәтә.Үзе белән кызыксына (мин кем?), үзе турында хәбәрләр туплый.Тирә-юньдәге предметлар һәм аларның кирәкле сыйфатлары белән кызыксына.Хайваннар, үсемлекләр дөньясы, табигатьтәге бәйләнеш белән кызыксына, күзәтүләрдә катнаша.

**Интегратив сыйфат ”Физик үсеш”**

Антропометрик күрсәткечләр нормада (буе, гәүдә авырлыгы).Яшенә туры килгән төп хәрәкәтләргә ия була.Хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаша, физик активлык вакытында уңай эмоция күрсәтә.Уеннар, физик күнегүләр белән кызыксына.Үзлектән культура-гигиена күнекмәләрен башкара.Үзлектән яисә өлекәннәр әйтүе буенча ашаганда, юынганда тәртип кагыйдәләрен белә.Культура-гигиена күнекмәләре сәламәтлек өчен кирәклеген аңлый.

**Интегратив сыйфат “Үз тәртибе белән идарә итә, үз гамәлләрен тормышка ашыра, гадәттәге норма һәм тәртип кагыйдәләрен саклый”**

Балалар бакчасында, урамда элементар тәртип нормаларын саклауда уңай карашка ия.Хәрәкәтле уеннарда, физик күнегүләр вакытында бергә эш итә белә. Бергәләп уеннарда элементар нормаларны сакларга әзер.Кычкырмыйча, тыныч кына аралаша ала.Ситуациягә карап тирә-юньгә изгелекле мөнәсәбәт күрсәтә: иптәше белән бүлешә белү, яхшы һәм начар кыланышларга дөрес бәя бирү.Дус яшәргә, уенчыклар белән бүлешергә, бер-береңә ярдәм итәргә кирәклекне аңлый.Әдәплелек нормаларын белә: үзлектән ”рәхмәт”,”саубулыгыз”,”исәнмесез”

сүзләрен әйтә белә.Киемендәге тәртипсезлекне күрә белә һәм өлкәннәр ярдәмендә бу хәлдән чыгу юлын эзли.Төркем бүлмәсен тәртиптә тотарга кирәклекне аңлый, белә. Уйнаганнан соң уенчыкларны үз урынына алып куя.

### 3.2. Төркемнең материаль-техник нигезе.

Барлык эксплуатацияләнүче бүлмәләр Санпин, хезмәт саклау, янгын сүндерү иминлеге, антитеррористик иминлек таләпләренә туры килә. **Җиһазлау.**

**Төркем бүлмәсе:**

- практик эшчәнлек өчен яракланган балалар җиһазлары;
- китап почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган китаплар, әкиятләргә иллюстрацияләр, пазл уеннары “Әкиятне җый”;
- тасвирлау эшчәнлеге өчен почмак (кәгазләр, карандашлар, пластилин, трафаретлар, буяулар, гуашь, пумалалар, бизәү үрнәкләре, яраксыз материаллар, сәнгать жанрларының үрнәкләре, рәсемнәре һ.б.;
- уен җиһазлары, с/р уеннар ( “Гаилә”, “Шифаханә”, “Тәмле кибете”, “Матурлык үзәге”) уеннарга атрибутлар;
- театр эшчәнлеге почмагы(театр төрләре папкасы, өстәл, бармак, шәүләле, кул һ.б театрлары);
- музыкаль эшчәнлек почмагы (музыкаль инструментлар: курай, шөлдерле барабан, барабан һ.б. музыкаль инструментлар, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, д/у);
- табигать почмагы (яшелчә, җимеш муляжлары, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, хезмәт почмагы: алъяпкычлар, лейкалар, кечкенә көрәкләр, тырмалар)
- конструкцияләү почмагы (төрле төрдәге конструкторлар: “Лего”, “Зур шакмаклар” )
- кул-бармак эшчәнлеге почмагы (шнуровка, массаж туплары, мозаика һ.б)
- өстәл, дидиактик, үстерүле уеннар почмагы;
- сенсор почмагы (Дьенеш блоклары, Киюзенер таякчыклары)
- туган тел почмагы (Г.Тукай портреты, аның әсәрләре җыентыгы, магнитафон, наотбук, с.д язмалар (әкиятләр, җырлар, бию көйләре) Яңа Кырлайдагы Г.Тукай иҗатына багышланган мемориаль музей комплексының альбомы , Болгар Дәүләтенә багышланган альбом һ.б. - физкультура почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган материал: х/у маскалар, туплар, кыршаулар, сикергечләр һ.б **Киенү - чишенү бүлмәсе.**
- Әти-әниләр өчен информацион-күргәзмә почмак (“Безнең тормыш”, “Меню”, “Котлыйбыз”, “Көндәлек режим”, “Турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенең челтәре”, “Сезнең өчен әти-әниләр”, “Белдерүләр”) - сәламәтләндерү почмагы (информацион материаллар).

## 3.3 Ата-аналар белән эш

Гаилә б-н эштә белем бирү юнәлешләре:

*«Сәламәтлек»:*

-ата-аналарга сәламәтлек факторлары турында мәгълүмат җиткерү(тыныч аралашу,туклану,чыныгу,хәрәкәтләнү).

*«Физик үсеш»:*

- Спорт уеннары белән баланың хәрәкәт активлыгын үстерү. *«Куркынычсызлык»:*
- ата-аналарны бала сәламәтлегенә куркыныч янаучы очраклар һәм тәртип кагыйдәләре белән таныштыру (өйдә ,яшелчә бакчасында,юлда, су буенда);
-ата-аналарны балалар белән бергә актив ял итәргә өндәү.

*«Социализация»:*

-ата-аналарны уен үсешендә кызыксындыру.

-бала тәрбияләүне гаилә белән бер юнәлештә алып бару.

*«Хезмәт»:*

- гаиләдә хезмәт тәрбиясен бирүне өйрәнү;
- гаилә белән берлектә бакчаны яшелләндерүдә катнашу.

*«Танып-белү»:*

- ата-аналарга балаларның танып-белүгә,аралашуга мохтаҗлыгын җиткерү; *«Коммуникация»:*
- ата-аналарда бала белән аралашу күнекмәсен үстерү; *«Матур әдәбият»:*
- ата-аналарга өйдә уку әһәмиятен аңлату.доказывать родителям ценность домашнего чтения;
- баланы матур әдәбият белән таныштыру ысулларын күрсәтү,җиткерү.

*«Нәфис иҗат»:*

- Ата -аналарның бакчада һәм өйдә балаларның иҗади эшчәнлеген үстерү омтылышын хуплау.
- ата-аналарны һәм балаларны иҗат үстерүче күмәк актив эшчәнлеккә өндәү.

*«Җыр»:*

- җыр мөмкинлекләренә баланың психик үсешенә уңай тәэсир итүче чара кебер карарга. кара программа «От рождения до школы» ред. Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой(. 267-273б.)

**ЧЫГАНАКЛАР:**

1).Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр” төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасы. Казан, “Хәтер”, 2016 ел;

2)_Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма. Казан,”Фолиант”,2013ел;

3) З. Г. ШӘРӘФЕТДИНОВА, И. Җ. ХӨБИБУЛИНА, Ф. В. ХӘЗРӘТОВА.Математикага өйрәнәбез.Методик әсбап.Казан,2010ел;

4) Р. М. ЗИННАТОВА, Л. Ә. ГАРӘЕВА, А. Г. ЗВОРЫКИНА.СУРӘТЛӘҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ КОНСТРУКЦИЯЛӘҮ.МЕТОДИК КУЛЛАНМА. КАЗАН, 2010ЕЛ;

5) Иң матур сүз.Уку китабы.”Мәгариф”нәшрияты,2000 ел.

И.О. Заведующего МБДОУ «Центр развития ребенка – детский сад № 85 «Карусель»

____________________ Г.Д.Ханнанова